ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
БАВЛИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАУЛЫ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

25.02.2026 ел Баулы шәһәре №35

Баулы муниципаль районы башкарма комитетының 2025 елның 4 апрелендәге 39 номерлы карары белән расланган, Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы гражданнар оборонасы һәм гадәттән тыш хәлләр буенча Виртуаль укыту-консультация пункты турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларына үзгәрешләр кертү турында» Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2026 елның 19 гыйнварындагы 7 номерлы карары нигезендә, Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы Башкарма комитетының 2025 елның 4 апрелендәге 39 номерлы карары белән расланган, гражданнар оборонасы һәм гадәттән тыш хәлләр буенча Виртуаль укыту-консультация пункты турындагы Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1 «Гомуми нигезләмәләр» бүлегендә:

өченче, бишенче һәм унберенче абзацларда «хәрби конфликтлар вакытында яисә шушы конфликтлар нәтиҗәсендә, шулай ук табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләр вакытында» сүзләрен «мобилизация чорында, хәрби хәл гамәлдә булган чорда, сугыш вакытында барлыкка килә торган» сүзләренә алмаштырырга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://www.pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы сайтында (http://www.bavly.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Баулы муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе Д.Л. Бакиров